**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Кармыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегеграждannары**
**җыены карары**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге составына керүче Яшәүче бистәсе торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

07 ноябрь 2019 ел №3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 1 ноябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2020 елда Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Кармыш, Яшәүче торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юл-урам челтәрендәге юл кырыйларын норматив хәлгә китерү, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;

- Кармыш, Яшәүче торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Кармыш авылы торак пунктларында урам юл челтәрендә чокырларны ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне(хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу

- Кармыш, Яшәүче торак пунктларында скважиналарны лицензияләү, суга экспертиза һәм анализ өчен түләү

- Кармыш, Яшәүче торак пунктларында зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, коймаларны (урнаштыру) ремонтлау һәм буяу, чүп савытларын урнаштыру, коры-сарыдан чистарту, керү юлларын, сукмакларны төзекләндерү, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект-смета документлары

өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу һәм башкарылган эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- 2015 ел өчен үзара салым акчаларының 148010 сум күләмендә калдыкларын куллану.

«ӘЙЕ» « ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының **54** катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны **30** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында **30** катнашучы тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен **0** катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге составына керүче Яшәүче торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2020 елда Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Кармыш, Яшәүче торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юл-урам челтәрендәге юл кырыйларын норматив хәлгә китерү, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;

- Кармыш, Яшәүче торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Кармыш авылы торак пунктларында урам юл челтәрендә чокырларны ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне(хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу

- Кармыш, Яшәүче торак пунктларында скважиналарны лицензияләү, суга экспертиза һәм анализ өчен түләү

- Кармыш, Яшәүче торак пунктларында зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, коймаларны (урнаштыру) ремонтлау һәм буяу, чүп савытларын урнаштыру, коры-сарыдан чистарту, керү юлларын, сукмакларны төзекләндерү, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект-смета документлары

өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу һәм башкарылган эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- 2015 ел өчен үзара салым акчаларының 148010 сум күләмендә калдыкларын куллану- карар кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: Яшәүче бистәсе, Совет ур., 26б. Чирмешән муниципаль районының рәсми интернет-сайтында бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Кармыш авыл җирлеге башлыгы: И.И.Фәтхетдинов